ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 166-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 166-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 17 марты
№ 590-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш), 2024, № 44 (I өлеш), № 76 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $10^1$ статьяда:
а) исемдә «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;
б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Депутат Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә (алга таба әлеге статьяда – Комиссия) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда һәм срокларда керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында әлеге Федераль законда каралган белешмәләрне тапшырырга тиеш. Депутат «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда чыгымнары турында әлеге Федераль законда каралган белешмәләрне тапшыра. Депутат, әгәр «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакмият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы

3 – 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аннан тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.»;

в) 2 пунктта «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;

г) 3 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. 1 пунктта каралган очракларда депутат түбәндәгеләрне тапшыра:»;

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнары турында белешмәләрне тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан алып 31 декабрен дә кертеп (хисап чорында) барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, бүтән түләүләрне кертеп) алынган керемнәре турындагы белешмәләрне, шулай ук хисап чоры ахырына милек хокукындагы үз мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне;

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнары турында белешмәләрне тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан алып 31 декабрен дә кертеп (хисап чорында) барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, бүтән түләүләрне кертеп) алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы белешмәләрне, шулай ук хисап чоры ахырына милек хокукындагы аларның мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне;

3 пунктчада «әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, үзенең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында һәм бу алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр» сүзләрен «әлеге затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, үзенең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында һәм бу алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 пунктта «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;

е) 5 пунктта «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;

ж) 6 пунктта «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;

2) $10^3$ статьяның 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган депутатлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган

белешмәләр хакындагы, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган депутатлар тарафыннан чыгымнары турында тапшырыла торган белешмәләр хакындагы мәгълүматтан, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, депутатлар тарафыннан белә торып тулы булмаган белешмәләрне тапшыру хакындагы йә Комиссия тарафыннан ачыкланган белә торып дөрес булмаган белешмәләрне тапшыру хакындагы мәгълүматтан файдалана алуны тәэмин итү федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3) $10^4$ статьяда:

а) исемдә «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;

б) 1 пунктта:

1 абзацта «20 апрельгә кадәр» сүзләрен «20 майга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктчада «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;

3 пунктчада «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;

2 пунктта «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;

4) $10^5$ статьяның 8 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутат әлеге Законның 6 статьясындагы $4^1$ пунктында, әлеге статьяның 1 һәм 3 пунктларында каралган чикләүләрне, тыюларны бозган һәм бурычларны башкармаган, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнары турында белешмәләрне тапшырмаган, яисә, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләрне йә белә торып дөрес булмаган белешмәләрне тапшырган очракта, аңа карата түбәндәге җаваплылык чараларының берсе күрелергә мөмкин:»

5) 4 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2021,

№ 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), 2026, № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторлары вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданнар керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган белешмәләр тапшырырга тиеш. Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторлары керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган белешмәләр һәм чыгымнар турында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган белешмәләр, әлеге федераль законнарда билгеләнгән очракларда, тапшырырга тиеш. Әлеге өлештә күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.»;

2) 4 өлештә «үз чыгымнары» сүзләреннән соң «турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә, «әлеге затның һәм аның хатынының (иренең)» сүзләрен «әлеге затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 93 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм күрсәтелгән вазыйфаларны били торган затлар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне вазыйфа буенча вәкаләт бирелгәндә (вазыйфага билгеләп куелганда, сайланганда) тапшырырга тиеш. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат әлеге өлештә күрсәтелгән белешмәләрне «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә затның чыгымнар турында белешмәләр тапшыруы өчен нигезләр барлыкка килгән очракта – мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш. Әлеге өлештә күрсәтелгән белешмәләр «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.».

**4 статья**

«Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

2) 1 статьяда:

а) 1 өлештә «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр,» сүзләрен «үз керемнәре, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр,» сүзләренә алмаштырырга, «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга, «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

3) 2 статьяда:

а) исемдә «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

в) 2 өлештә «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

г) 3 өлешнең 3 пунктында «үз чыгымнары» сүзләрен «үз чыгымнары турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга, «әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән» сүзләрен

«әлеге гражданның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда һәм срокларда түбәндәгеләрне тапшыра:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан алып 31 декабренә кадәр (хисап чоры) барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган үз керемнәре турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына милек хокукындагы үз мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан алып 31 декабренә кадәр (хисап чоры) барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына милек хокукындагы аларның мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;»;

3 пунктта «үз чыгымнары» сүзләрен «үз чыгымнары турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга, «әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән» сүзләрен «әлеге гражданның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән» сүзләренә алмаштырырга;

е) $4^1$ өлештә:

беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

икенче абзацта «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;

өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

ж) 5 өлештә «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга;

з) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Тиешле муниципаль районда (шәһәр округында) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи зат ел саен 20 апрельгә кадәр җирле үзидарә органының рәсми сайтында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан әлеге статьяның 4 өлешендә билгеләнгән бурычның үтәлеше

(тиешенчә үтәлмәве) турында гомумиләштерелгән мәгълүмат урнаштыра (мондый мәгълүматта тиешле затны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган персональ белешмәләр һәм тиешле затныкы булган мөлкәтне индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган белешмәләр булмау шарты үтәлгәндә), анда түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

1) тиешле муниципаль берәмлекнең (муниципаль районның, җирлекнең, шәһәр округының) вәкиллекле органының сайланган депутатлары саны;

2) тиешле муниципаль берәмлекнең (муниципаль районның, җирлекнең, шәһәр округының) вәкиллекле органының керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәгән депутатлары саны;

3) тиешле муниципаль берәмлекнең (муниципаль районның, җирлекнең, шәһәр округының) вәкиллекле органының керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру бурычын тиешенчә үтәмәгән депутатлары саны.»;

4) 3 статьяда:

а) исемдә «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә «чыгымнары,» сүзен төшереп калдырырга, «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

в) 3 өлештә «әлеге Законның 2 статьясындагы 4 һәм $4^1$ өлешләрендә күрсәтелгән» сүзләрен «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

5) 4 статьяда:

а) исемдә «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

в) 2 өлештә «чыгымнар,» сүзен төшереп калдырырга;

6) Законга кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль законны (алга таба – Федераль закон) үтәү максатыннан эшләнде.

Әлеге Федераль закон белән, башкалар арасында, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын һәм муниципаль вазыйфаларны, шулай ук контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе үзгәртелде.

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән норма беркетелә, аның нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар (шул исәптән үз вәкаләтләрен даими нигездә һәм даими нигездә булмаган башкаручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары), муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар (башкарма комитетлар җитәкчеләре) тарафыннан әлеге белешмәләр элеккечә ел саен түгел, ә җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча белешмәләр тапшыру елыннан алдагы (хисап чорында) календарь ел дәвамында алыш-биреш башкарылган очракта, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы тиешле вазыйфаны биләүче затның, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның хисап чорыннан алдагы өч елдагы гомуми кеременнән артса, тапшырылачак. Мондый белешмәләр алыш-биреш башкарылган елдан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырылачак.

Шулай ук Федераль законда җирле үзидарә органының рәсми сайтында муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәү (тиешенчә үтәмәү) турында гомумиләштерелгән мәгълүматны урнаштыру тәртибе Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә дип беркетелә.

Шул уңайдан, әлеге закон проекты белән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары депутатларына карата күрсәтелгән тәртип билгеләнә.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указына, шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында» Указына, шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чикләүләрне үтәүне тикшерү тикшерү турында» 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-233 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.